
**“Кар бөртекләре җыю»**

Бүлмә идәненә кар бөртекләре сибеләә. Уенда ике бала катнаша. Аларга матур тартма бирелә. Тәрбияче сигналы буенча, балалар кар бөртекләрен җыеп, тартмаларга салалар. Алдан кайсы җыеп бетерсә, шул бала җиңүче була

***Бергәләп өйрәник***



# ***Кыш***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(6-7 яшь)***

**Тизәйткеч «Шуа-шуа шомара».**

Чаңгычының чаңгысы
Шуа-шуа шомара.
Чаңгың шомарсын дисәң,
Кирәк ешрак шуарга.
Шаһидәнең чаңгысы
Шома әнә шуңарга

## Сынамышлар
## «Халык әйтсә – хак әйтә».

а) Кыш бәс, томан булса, җәй иген уңа.
б) Кыш карсыз булса, җәй ярлы була.
в) Кар калын булса, ашлык уңар.
г) Каз аягын күтәреп торса, салкын булыр.
д) Төтен җиргә төшсә, кышын кар явар.
е) Кояш бик еракта булып күренсә, салкын булыр.
ж) Тау башларында кар күп булса, җиләк күп булыр.

**Кыш килде**
Килеп җитте кыш та.
Ай-яй, салкын тышта...
Өч ай торыр торса,
Аның гомере кыска...
Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән;
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Саф һавага чыгып,
Таудан чана шуып,
Кышның салкыннарын
Җибәрәбез, куып.
Бари Рәхмәт

**Буранда**
Беркем чыкмый урамга,
Буранлы көн булганга.
Буран ала бөтереп,
Салкын ала өттереп!
Кошлар гына һавада
Чайкалалар һаман да.
Рәхәтләнеп очарга
Бик кыендыр кошларга.
Р.Миңнуллин.

**Сүзле-хәрәкәтле уен «Кышкы паркта».**
Кышкы паркка килдек,
Матур урыннар күрдек.
Тун кигән каен уңда,
Ямь-яшел чыршы – сулда.
Кар бөртекләре оча,
Әйләнеп, җирне коча.
Кызылтүшләр очалар,
Бигрәк матур алар.
Паркта рәхәт булса да,
Өйгә кайтыйк, балалар.

## Хәрәкәтле уеннар
## Чаналарга!

Чаналарны мәйданчыкның бер ягына урнаштыралар. Аларның саны уйнаучылардан бергә кимрәк булырга тиеш. Мәйданчыкның икенче каршында балалар йөгереп йөриләр, әйләнәләр, сикергәлиләр. Тәрбияче: «Чаналарга!»- дип сигнал бирә, балалар чаналарга таба йөгерәләр һәм тиз генә берәр чанага утыралар. Иң соң-гы килгән бала урынсыз кала.